СОВЕТ УСАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.4, с. Усали,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ҮСӘЛИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Беренче май ур., 4 нче йорт, Үсәли авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422174

тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

« 20 » сентябрь 2017 ел № 2-23

## Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 23.03.2004 № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Үсәли авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдумны үткәрергә:
««Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1.Торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итү, су чыгару оештыру:
Үсәли торак пунктында , Югары Берсут торак пунктында су алу скважинасын саклау;
Усали торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү һәм ремонтлау Татарстан урамы, Беренче Май урамы;
Берсут-Сукаче торак пунктында су күтәрү манарасын сатып алу һәм урнаштыру; Дружба , Кук-Чишмә торак пункты торак пунктларында чишмәне ремонтлау

2.Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын тоту: Югары Берсут торак пунктындагы зиратны әйләндереп алу..

**3. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

Владимир авылында совет, Беренче Май урамнарында, Үсәли торак пунктында Татарстан урамында юлларны вак таш җәеп ремонтлау;

4. Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

Үсәли, Югары Берсут, Владимирово, Берсут-Сукаче авылларында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

«ӘЙЕ» «ЮК»

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Үсәли авыл җирлеге Башлыгы А.И.Зиатдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Үсәли авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /А.И.Зиатдинов /